Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Яңа Имән авыл җирлеге Күтәмәле авыл
ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«14» ноябрь 2019 ел. № 1

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлегендә Күтәмәле авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары нигезендә 2019 елның 15 ноябрендә «2020 елда һәр балигъ булган гражданнан 250 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә килешәсезме? " мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде., Яңа Имән авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән (1 төркем инвалид, ялгыз карт гражданнар, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш), һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрү турында Карар кабул ителде:

- Күтәмәле авылында урам утларына яңа энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру һәм искеләрен төзекләндерү;
- төзекләндерү буенча хезмәт күрсәтүчеләргә түләү (территорияне чистарту, үләннәрне чабу));
- Күтәмәле авылында аншлагларны яңарту, зират коймаларын буяу өчен буяулар сатып алу;;
-"Беларусь-82,1" тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запчастьләр сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт хакы түләү);
- Күтәмәле авылында үлән чаптыру өчен триммер сатып алу;
- Күтәмәле авылында кышын җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту;
- Күтәмәле авылындагы Гагарин, Пушкин, Гатауллин Рахматулла, Тукай урамнарының асфальт түшәмәсендәге чокырларны ремонтлау;
- Җиңү көне, Сабантуй, өлкәннәр көне бәйрәмнәрен үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;

"ӘЙЕ" "ЮК".

14.11.2019 елдагы гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 213 кеше, гражданнар җыенында катнашучылар саны 174 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 174 кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлегендә, Сарман муниципаль районы Күтәмәле авылында узган халык җыенын халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Яңа Имән авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 нче төркем инвалидларыннан, ялгыз карт гражданнардан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, 2020 елда үзара салым акчаларын кертүгә килешәсезме, һәм алган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү турында Карар кабул ителгән дип танырга («әйе»- 174, «юк» - 0).:

- Күтәмәле авылында урам утларына яңа энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру һәм искеләрен төзекләндерү;
- төзекләндерү буенча хезмәт күрсәтүчеләргә түләү (территорияне чистарту, үләннәрне чабу));
- Күтәмәле авылында аншлагларны яңарту, зират коймаларын буяу өчен буяулар сатып алу;;
-"Беларусь-82,1" тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запчастьләр сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт хакы түләү);
- Күтәмәле авылында үлән чаптыру өчен триммер сатып алу;
- Күтәмәле авылында кышын җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту;
- Күтәмәле авылындагы Гагарин, Пушкин, Гатауллин Рахматулла, Тукай урамнарының асфальт түшәмәсендәге чокырларны ремонтлау;
- Җиңү көне, Сабантуй, өлкәннәр көне бәйрәмнәрен үткәрү өчен бүләкләр сатып алу.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http//sarmanovo.tatar.ru һәм Күтәмәле авылы, Гагарин урамы, 39 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә .

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче ,

Яңа Имән авыл җирлеге башлыгы Гараев Р.Ф.Гараев